ГЛАВА МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

25.10.2023 с. Майдан № 2

Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Ясная Звезда авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 7 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Ясная Звезда авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Ясная Звезда авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә риза булырсызмы:

- Ясная Звезда авылында урам яктырту системасын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Ясная Звезда авылы, Урман урамы, 16нчы йорт адресы буенча 8.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

ТР Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев